РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

23.06.2015 ел №289

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен кабул итү турында» 2015 елның 8 апрелендәге 281 номерлы карарын гамәлдән чыгару турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставының 71 статьясы нигезендә, килешү проекты Татарстан Республикасы Прокуратурасы белән килештерелмәгән һәм законнарга туры килми дип танылуны исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советының «Дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү вәкаләтләрен кабул итү турында» 2015 елның 8 апрелендәге 281 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре Советларына «Дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән эш итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында» кабул ителгән карарларны, гамәлдәге законнарга туры килми дип, гамәлдән чыгаруны тәкъдим итәргә.
3. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләре башкарма комитетлары белән элек төзелгән, авыл җирлеге территориясендә урнашкан дәүләт милке чикләнмәгән һәм авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре белән эш итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында килешүләрне, авыл җирлегеннән файдалану һәм төзелеш алып бару буенча расланган кагыйдәләр булганда, өзәргә тиеш

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы урынбасары,
муниципаль район советы рәисе урынбасары М.Т. Батыршина